**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**СОВЕТЫ**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 60** **2019 елның 12 сентябре**

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль район Советының «Түбән Кама муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм эш алып бару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 40 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында һәм Түбән Кама муниципаль район Советының «Түбән Кама муниципаль районының муниципаль милеге реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 25 декабрендәге 70 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 30 статьясы нигезендә, муниципаль милек белән нәтиҗәле файдалану һәм идарә итү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм эш алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Түбән Кама муниципаль районының муниципаль милкен биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

9.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.2. Муниципаль милек физик һәм (яки) юридик затлар милкенә бары тик түләүле нигездә генә бирелә (муниципаль унитар предприятиеләрне үзгәртеп кору юлы белән төзелгән Хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталына муниципаль милектәге акцияләрне яки акцияләрне муниципаль милеккә тапшыру юлы белән).»

9.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.8. Муниципаль милекне хосусыйлаштырганда түбәндәге хосусыйлаштыру ысуллары кулланыла:

1) унитар предприятиене акционерлык җәмгыятенә әверелдерү;

1.1) унитар предприятиене җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять итеп үзгәртеп кору;

2) муниципаль мөлкәтне аукционда сату;

3) махсуслаштырылган аукционда акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен сату;

4) конкурста муниципаль милекне сату;

5) акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен Россия Федерациясе территориясеннән читтә сату;

6) муниципаль мөлкәтне халык алдында тәкъдим итү юлы белән сату.;

7) муниципаль милекне бәяне игълан итмичә сату;

8) акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына өлеш буларак муниципаль мөлкәт кертү.;

9) ышанычлы идарә итү нәтиҗәләре буенча акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен сату.»

9 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 9.8.1 пункты белән тулыландыдырга:

«9.8.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы 21.12.2001 ел, № 178 - ФЗ Федераль законның 18-20, 23, 24 статьяларында билгеләнгән ысуллар белән сату электрон формада башкарыла.»;

9.12 пунктның 1 абзацында "бер елдан өч елга кадәр" сүзләрен төшереп калдырырга;

10.2-10.4, 16.3 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

16.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.5 муниципаль милек реестры Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алып барыла».

2. Түбән Кама муниципаль район Советының «Түбән Кама муниципаль районының муниципаль милеге реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 25 декабрендәге 70 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р. Метшин